РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ГЛАВА ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

Ленина ул., д. 46, с. Тюлячи, 422080

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

Ленин ур., 46 нчы йорт, Теләче авылы, 422080

тел. (факс): (843) 602-11-89, E-mail: telache@tatar.ru, http://tulachi.tatarstan.ru/

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 68 «20» декабря 2018 г.

Теләче муниципаль районы территориясендә иң яхшы яңа ел бизәлешенә конкурс үткәрү турында

Теләче муниципаль районы территориясендә яңа 2019 ел башлануын бәйрәм итү һәм ял итүне оештыруга шартлар тудыру, биналарны, урамнарны, паркларны, яңа ел чыршыларын сәнгатьчә, яктылык белән бизәлешен яхшырту максатыннан

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Теләче муниципаль районы территориясендәге предприятиеләр һәм оешмалар, авыл җирлекләре арасында 2018 елның 25 декабреннән 2019 елның 14 гыйнварына кадәр иң яхшы яңа ел бизәлешенә конкурс игълан итәргә һәм уздырырга.
2. Теләче муниципаль районы территориясендә иң яхшы яңа ел бизәлешенә конкурс турында Нигезләмәне № 1 Кушымтага туры китереп расларга.
3. Теләче муниципаль районы территориясендә иң яхшы яңа ел бизәлешенә конкурс оештыру һәм нәтиҗәләр чыгару өчен комиссия составын № 2 Кушымтага туры китереп расларга.
4. Комиссия эшенең нәтиҗәләре буенча тиешле документлар әзерләргә.
5. Теләче муниципаль районы финанс- бюджет палатасына (Яхин Р.Р.) расланган Нигезләмә буенча җиңүчеләрне бүләкләү өчен акча средстволары табарга.
6. Әлеге боерыкның үтәлешенә контрольне Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А. А. Нурмөхәммәтовка йөкләргә.

И. Ф. Зарипов

Теләче муниципаль районы
Башлыгының 2018 елның
«20» декабрь 68 санлы
Карарына Кушымта № 1

Теләче муниципаль районы территориясендә иң яхшы яңа ел бизәлешенә конкурс турында

НИГЕЗЛӘМӘ

1. Конкурсның бурычлары:

Иң яхшы яңа ел бизәлешенә конкурс (алга таба Нигезләмә текстында – конкурс) 2018 елның 25 декабреннән 2019 елның 14 гыйнварына кадәр, Теләче муниципаль районы территориясендә ял итүне оештыру өчен шартлар һәм бәйрәм рухы тудыру, биналарны, урамнарны, паркларны, яңа ел чыршыларын сәнгатьчә, яктылык белән бизәлешен яхшырту максатыннан, уздырыла.

2. Конкурста катнашалар:

2.1. Теләче муниципаль районы территориясендә урнашкан милекчелек формасына һәм оештыру-хокукый формаларга бәйле булмаган предприятиеләр һәм оешмалар (коммерцияле һәм коммерцияле булмаган оешмалар), юридик затларның Теләче муниципаль районы территориясендә урнашкан аерым бүлекчәләре (филиаллар, вәкиллекләр, бүлекләр һ. б.), законнар белән билгеләнгән тәртиптә шәхси эшмәкәр сыйфатында теркәлгән һәм эшмәкәрлек эшчәнлеген Теләче муниципаль районы территориясендә алып баручы физик затлар;

2.2. Берәмлек территориясендә урнашкан юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр, төп, урта (тулы) белем бирү учреждениеләре, һөнәри белем бирү учреждениеләре, балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләре, башлангыч гомуми белем бирү учреждениеләре һәм мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре арасында конкурсның гомумиләштерелгән нәтиҗәләре буенча «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы» муниципаль берәмлек составына керүче авыл җирлекләре;

3. Яңа ел бизәлешенә таләпләр:

– территориядә бизәлгән яңа ел чыршысы;
– кардан ясалган әкият персонажлары;
– кардан ясалган балалар уен мәйданчыгы булуы;
– электр һәм янгын куркынычсызлыгы таләпләрен һәм законнар нигезендә башка мәҗбүри таләпләрне үтәү.

4. Конкурста бәя бирү критерийлары:

– яңа ел чыршысының, бинаның, якын-тирә территориянең (боз шәһәрчекләре, кардан сыннар, таучыклар) үзенчәлекле бизәлеше, инновацион якын килү;
– бизәлешнең бина фасады белән туры килүе, тирә-юнь ландшафты белән гармониялелеге, сәнгать дәрәҗәсендә булуы;

– яктылык-иллюминацион бизәлеше;

– яңа ел чыршысының, кардан ясалган әкият персонажларының һәм кардан балалар уен мәйданчыгының тышкы кыяфәте (купшылыгы, чыршы уенчыкларының төрлелеге һ. б.), гомуми тәэсир итүе.

5. Катнашучыларга бәя бирү:

Конкурста катнашучыларга бәя Теләче муниципаль районы территориясендә иң яхшы яңа ел бизәлешенә конкурс оештыру һәм нәтиҗәләр чыгару комиссиясе тарафыннан бирелә. Комиссия карары утырышта катнашучы комиссия әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә һәм беркетмә белән беркетелә. Тавышлар тигез булган чоракта, конкурс комиссиясе рәисенең тавышы хәлиткеч булып санала.

Конкурс комиссиясе карары конкурс комиссиясе утырышы Беркетмәсенә кертелә һәм конкурс комиссиясе рәисе, тавыш бирүдә катнашкан комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана.

Конкурс нәтиҗәләре буенча җиңүчеләргә призлы урыннар аерым бирелә:

а) предприятиеләр һәм оешмалар арасында;

б) берәмлек территориясендә урнашкан юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр, төп, урта (тулы) белем бирү учреждениеләре, һөнәри белем бирү учреждениеләре, балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләре, башлангыч гомуми белем бирү учреждениеләре һәм мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре арасында конкурсның гомумиләштерелгән нәтиҗәләре буенча авыл җирлекләре арасында.

6. Призлар фонды

Конкурста призлы урыннарны алучылар премияләр белән түбәндәге таблица буенча бүләкләнә

| | **I урын** | **II урын** | **III урын** | **Барлыгы** |
|---|---|---|---|---|
| Предприятиеләр һәм оешмалар | 5000 сум | 3000 сум | 2000 сум | 10000 сум |
| Авыл җирлекләре | 5000 сум | 3000 сум | 2000 сум | 10000 сум |
| Барлык сумма | 10000 сум | 6000 сум | 4000 сум | 10000 сум |

Теләче муниципаль районы
Башлыгының 2018 елның
«20» декабрь 68 санлы
Карарына Кушымта № 2

Теләче муниципаль районы территориясендә иң яхшы яңа ел бизәлешенә конкурс оештыру һәм нәтиҗәләр чыгару буенча комиссия составы:

Комиссия рәисе

Хәмидуллин И.Х. - Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе.

Комиссия рәисе урынбасары;

Нурмөхәммәтов А.А. - Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары,

Комиссия әгъзалары:

Мөбинов И.В. - Теләче муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе (килешү буенча);
Миннегулов И.А. - Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең территориаль үсеш һәм инвестиция эшчәнлеге буенча урынбасары;
Һадиев И.Т. - Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының эшләр буенча идарәчесе;
Яхин Р.Р. – район Башкарма комитетының финанс-бюджет палатасы рәисе;
Иксанов Д.И. - район Башкарма комитетының мәдәният бүлеге җитәкчесе;
Карпова Н. В. – «Район Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесе җитәкчесе;
Гыйниятуллин И. С. – район башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм буенча бүлек җитәкчесе.